# КАРАР

**23 октябрь, 2023 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Мәмәшир авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 23 нче октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

" Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк кешеләрдән, 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләрдән,18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, 80 һәм аннан өлкәнрәклрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2024 елда һәр бэлигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?:

- Мәмәшир авылындагы урам - юл челтәрен төзекләндерү,ремонтлау ,щебенка җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.
- тирән насослар сатып алу һәм урнаштыру , Мамашир авылын су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау , проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Мәмәшир авылы урамын яктыртуны көйләү өчен урам утлары һәм махсус җиһазлар сатып алу ,ремонтлау;
- Мәмәшир авылы территориясен төзекләндерү;
- җирлек территориясендә физик культура үсеше өчен шартлар тәэмин итү;
- Мәмәшир авылында урамнарны яктыртуны җайга салу өчен урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу .
- янгын гидрантларын комплектлау өчен сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру ;

җәяүлеләр күпере төзелеше һәм ремонтлау, автомобиль күпере ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 544 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 308 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 308 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Мәмәшир авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк кешеләрдән, 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләрдән,18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, 80 һәм аннан өлкәнрәкләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2024 елда һәр бэлигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?:

- Мәмәшир авылындагы урам - юл челтәрен төзекләндерү,ремонтлау ,щебенка җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

- тирән насослар сатып алу һәм урнаштыру , Мамашир авылын су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау , проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Мәмәшир авылы урамын яктыртуны көйләү өчен урам утлары һәм махсус җиһазлар сатып алу ,ремонтлау;

- Мәмәшир авылы территориясен төзекләндерү;

- җирлек территориясендә физик культура үсеше өчен шартлар тәэмин итү;

- Мәмәшир авылында урамнарны яктыртуны җайга салу өчен урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу .

- янгын гидрантларын комплектлау өчен сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру ;

-җәяүлеләр күпере төзелеше һәм ремонтлау, автомобиль күпере ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль

берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов